РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.06.2016 № 833-п

«Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 мартындагы 267-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының 16.02.2011 № 34-ОД боерыгы, Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны җайга салу максатларында, Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 10 мартындагы 267-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә 267-п номерлы стационар булмаган сәүдә объектлары белән тулыландырырга (кушымтада бирелә);
2. Әлеге карарны Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гасимов